

Инде декабрь – ноябрь айларынын берничә атнасы рәттән Торбеево районында яшәvчеләрнен кош-кортнын кvпләп vлvе борчу уята.Кvпчелек торак пунктлардагы ярдәмче хужа-лыкларда тавыклар саны кискен кимеде. Кошлар һәлак булуга нәрсә сәбәп булды һәм бу авыруны ничек туктатырга дигән сорауга Торбеево ветстанциясе баш табибы Юрий Киселев жавап кайтарган:- Без квартал саен мониторинг тикшеренvләре vткәрәбез. Бvген кvп кенә хужалыкларда тавыклар бактерия характерындагы «аринготрахеит» дип аталган авырудан vлә. Бу тавык отрядындагы кошларнын кискен йогышлы сулыш авыруы, трахеянын катараль-геморрагик ялкынсынуы, борын куышлыгы, авыр сулыш һәм йоткерv белән характерлана. Бу авыру сезонлылар рәтенә керә; ул һава торышынын vзгәрvе белән бәйле.       Яшь тавык һәм чебиләрдә авыру кошны ин начар шартлар булган башка бvлмәләргә кvчергәннән сон (дымлылык арту, вентиляция житмәv, начар туклану һ.б.) барлыкка килә.Авыру таралу факторлары булып терлек азыгы, су, аяк киеме һәм авыру кош-корт, пычранган кием хезмәт итә. Инфекция аэрогеник рәвештә була. Йоткергәндә авыру тавык вирус булган кечкенә тамчыларны һавага чыгарып жибәрә. Кыргый кош, тычканнар авырунын механик векторлары булырга момкин. Гадәттә салкыннар килv белән тавыкларнын vлеме кvзәтелә. Климат шартларынын кискен vзгәрvе кош-корт-ларда иммунитетнын зә-гыйфьләнvенә китерә, шунын белән торле бактерия инфекцияләре барлыкка килә, еш кына алар зәгыйфь урынга - vпкәләргә һәм бронхларга тәэсир итә. Әлбәттә, зур vлемнән сакланырга момкин. Ветеринария кагыйдәләре буенча, тавыклар билгеле бер температурада булырга тиеш. Сквозняклар булмавы, салам белән капланган чиста идән кош-кортка инфекция эләкмәскә булышачак. Әгәр бер-ике тавыкнын авырып китvен кvрсәгез, аларны сәламәтләреннән аерырга, ә калган малга антибиотик терапия vткәрергә кирәк.

Баш ветеринария табибы фикеренчә, әлеге тавык авыруы кешеләр очен куркыныч тудырмый. Әгәр дә сез кош авыру икәнен кvрсәгез, антибиотик терапия vтv очен, билгеләнгән ветстанциягә морәжәгать итәргә кирәк. Бинада дезинфекция ясарга кирәк.

**Раиса АГИШЕВА**